وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклапябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

# ДИН вә Мәгыйшәт

№2 (171). 11 гыйнвар 2013 / 29-сәфәр-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



"Мөхәммәдия" мәдрәсәсе

▷2◁



Вакытыгызның кадерен белегез!

▷2-3◁



Мәчеттә яланаяк һәм башка түбәтәй кими намаз уку мәкруһ гамәл булып исәпләнәме?

▷4◁

# МӘҮЛИД АЕ

**Тиздән мөселманнар өчен зур тантана, шатлык көне - Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (сгв) туган көне - Мәүлид бәйрәме җитә. Аны рабигыль-әүвәл аеның 12 нче көнендә билгеләп үтәләр.**



Сабый баланың дөньяга аваз салуы - аның әти-әнисе һәм туганнары өчен куанычлы вакыйга. Ә пәйгамбәр туу ул - бөтен дөнья өчен шатлык. Коръәни-Кәримдә болай диелә: "(Ий,Мөхәммәд) Без сине бары тик рәхмәт билгесе итеп галәмдәге халыкларга күндердек" ("Әнбия (Пәйгамбәрләр)" сүрәсенең 107 нче аяте). Сөекле пәйгамбәребез туган көнне безгә шәфкать-рәхим иңә. Аллаһы Тәгалә күрсәткән тугры юлны өйрәтүче Пәйгамбәребезнең (сгв) кешелек өчен мөһимлеген һәм күркәм сыйфатларын аңлаган очракта, Мәүлид ән-Нәби кебек көнгә битараф калып булмый.

Бу көнне бөтен дөнья мөселманнары Аллаһы Тәгаләнең пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) белән җибәргән рәхмәтен тагын бер кат төшенергә тырышырга һәм шөкрана кылып догалар укырга, пәйгамбәребезне мактап, салаватлар әйтергә тиешләр.

Мәүлид бәйрәмен билгеләп үтү - барлык мөселман халыкларына хас дини гореф-гадәтләрнең берсе. Ислам диненең күпчелек галимнәре бу көнне бәйрәм итү шәригать кануннары кысаларында башкарылса рөхсәт ителә, хәтта мәслихәт тә дигән фикердә. Бәйрәмне уздыру бит бары динебезне көчәйтә торган гамәлләрдән генә тора: бергәләп намазлар уку, салаватлар әйтү, Пәйгамбәребезнең (сгв) күркәм сыйфатлары турында сөйләшергә җыелу, догалар уку... Мәүлидне бәйрәм итүнең балалар өчен тәрбияви ягы да бар, чөнки бу көнне алар Пәйгамбәребез (сгв) турында еш ишетәләр, ә аның тормышын чагылдырган хикәятләр балаларны илһамландыра, күңелләрен баета.

Мәүлид - барлык мөселманнар өчен Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен искә төшерү. Раббыбызга рәхмәтле булыйк, шөкрана кылыйк, дин кардәшләребез белән бергә пәйгамбәребезгә багышлап һәм дөнья мөселманнары арасында тынычлык урнашуын сорап догалар кылыйк.

**Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ**

# ОЛУГ ГАЛИМ ВӘ ФИКЕР ИЯСЕ

**Моннан нәкъ тугыз гасыр элек яшәгән галим һәм җәмәгать эшлеклесе, педагог һәм остаз-имам Газзәлинең фикерләре, карашлары, аның хезмәтләре еллар аша урта гасырларда ук Европага барып ирешә, бөек немец философы Гегель тарафыннан да бик югары бәяләнә.**

Әл-Газзәли әбү-Хәмид Мөхәммәд - күренекле ислам дине белгече һәм фикер иясе 1058 елда Иранның Тус шәһәрендә (әлеге кала Хөрәсән төбәгендә урнашкан) туган. Аның балачагы ятимлектә һәм михнәттә узган. Тус, Җурҗан һәм Нишапурдагы атаклы мәдрәсәләрдә белем алган.

1085 елда Коръәнне тирәнтен үзләштергән һәм аны оста итеп тәфсир кылучы буларак, аны вәзир Низам әл-Мөлек Исфаханга китертә һәм Иранны яулап алган сәлҗүк солтаны Мәлик шаһ сараена хезмәт итәргә күндерә. Мәгълүм булганча, шул чорларда шунда бөек шагыйрь, математик һәм астроном Гомәр Хәйям дә яши.

Бу ике шәхеснең очрашуы турында риваять бар. Имеш, бервакыт Газзәли Исфахандагы обсерваториягә килә һәм үзеннән 10 яшькә өлкәнрәк Гомәр Хәйям белән озаклап әңгәмә кора. Кунак акыл иясенең йолдызлар, галәм төзелеше, обсерваториянең эшчәнлеге турында тәфсилләп сөйләвен шаккатып тыңлый, сораулар яудыра. Әңгәмәдәшләр сүз белән шулкадәр мавыгып китәләр ки, хәтта вакыйгаларның чылбырын югалтып, сүзне ничек йомгакларга белмиләр. Шулчак манарадан азан ишетелә һәм әл-Газзәли:

- Ниһаять, бөек хакыйкать ишетелде һәм сафсата эреп югалды, - дип, обсерваториядән чыгып китә.

Гыйлем эстәүнең әһәмиятен тирәнтен аңлаган Низам әл-Мөлек Мәлик шаһны илдә берничә урында дарелфөнүн ачарга күндерә. Табигыйдер, мәгърифәт учаклары кодрәт иясе вәзир хөрмәтенә "Низамийя" исеме белән аталалар. 1091 елда Багдад шәһәрендәге "Низамийя"гә вәзир Ислам дине хокукын - фикъһе мөгаллиме итеп Газзәлине җибәрә. Мәгәр аның укытучылык эшчәнлеге нибары дүрт ел гына дәвам итә. Тәхет тирәсендә вакыйгалар куера. Вәзир Низам әл-Мөлек һәм Мәлик шаһ фетнәчеләр тарафыннан явызларча үтерелә һәм, сәлҗүкләр империясеннән бәрәкәт качып, ызгыш-тарткалашлар башлана. Белгечләр фаразлаганча, әлеге куркыныч вакыйгалар тәэсирендә, әллә инде башка сәбәпләр беләнме галим авыруга сабыша һәм Шамнан (Багдадтан) хаҗ сәфәренә чыгып китә. Хаҗдан соң Газзәли суфиларга кушыла. Дистә еллар буе



*(Ахыры 3-4 нче битләрдә.)*

## ЯҢАЛЫКЛАР

**ХӘЛӘЛ РИЗЫК ҖИТЕШТЕРЕРГӘ ТЕЛӘҮЧЕЛӘР АРТА**

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең "Хәләл" стандартлары комитеты динебез кануннары буенча продукция әзерләүне раслый торган таныклыклар тапшырды.** Комитет таныклыкларын бу юлы май ризыкларын җитештерүче "Клюкин Вячеслав Владимирович" шәхси предприятиесе һәм "Молочное объединение "Победа" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте алды. Әлеге оешмалар икесе дә - Чиләбенеке. Таныклыклар бер елга бирелде.

**"ЗӘКЯТ" ФОНДЫ ЭШ ТАБАРГА ЯРДӘМ ИТӘ**

**Татарстан мөфтиятендәге "Зәкят" хәйрия фонды социаль мәсьәләләрне хәл итү белән шөгыльләнә һәм ятимнәргә, өлкәннәргә, авыруларга, инвалидларга, мохтаҗларга хәйрия ярдәме күрсәтә.** Иң беренче чиратта хезмәткә яраксыз кешеләргә өстенлек бирелә.

Әмма безнең җәмгыятебездә, эшкә яраклы булып та, билгеле бер сәбәпләр аркасында эш таба алмаучылар бар. Менә шундыйларга ярдәм күрсәтү максатыннан, "Зәкят" фонды Казанда кадрлар белән эшләүдә әйдәп баручылардан саналган "Уңыш стратегиясе" компаниясе белән килешү төзеде. Хәзер фонд мохтаҗларны эшкә урнаштыру белән шөгыльләнәчәк.

2013 елда, бу максатны күздә тотып, Казанның Кабан арты мәчетендә яңа профессия үзләштерү чаралары, тренинглар, мастер-класслар үткәреләчәк.

**Өстәмә мәгълүмат алу өчен телефон: +7 (843) 537-12-83.**

**ӘГЕРҖЕДӘ МӘҮЛИДКӘ ӘЗЕРЛӘНӘЛӘР**

**Әгерҗе мөхтәсибәте Мәүлид бәйрәменә әзерләнә. Белгәнебезчә, быел Мәүлид - Мөхәммәд пәйгамбәрнең (сгв) туган көне - 24 гыйнварга туры килә.**

Әгерҗе районы имам-мөхтәсибе Хәлим хәзрәт Якупов хәбәр иткәнчә, районда изге бәйрәм кичәсен үткәрү өчен әзерлек эшләре башланган. "Районыбызның "Нур" мәдрәсәсендә өлкәннәр Пәйгамбәребезне (сгв) олылаган мөнәҗәтләр, балалар шигырьләр өйрәнә. Мәүлид бәйрәмен гыйнвар ахырында район хакимияте белән берлектә Мәдәният йортында зурлап уздырырга җыенабыз", - диде Хәлим хәзрәт.

**ЛЕНИНОГОРСКИДА БАЛАЛАРНЫҢ ЯЛЫ ФАЙДАЛЫ УЗДЫ**

**Лениногорск шәһәре, Керкәле, Яңа һәм Иске Шөгер, Бәкер авыллары мәчетләренә барлыгы иллеләп бала җыелды.**

Мәктәп балалары ялга туктаган вакытта, алар өчен мәчетләрдә белем бирү генә түгел, ял итү чаралары да оештырылды. Быел әлеге чаралар җиденче мәртәбә үткәрелде. Балаларга иң беренче чиратта дин нигезләре өйрәтелде. Бу дәресләр ярдәмендә балалар әти-әниләрне, өлкәннәрне хөрмәтләргә, дус-ишләренә үрнәк, күркәм холыклы булу нихәтле әһәмиятле икәнен белделәр. Төрле ярышларда катнашып, бүләкләр дә алдылар. Саф һавада уйнап, сәламәтлекләрен ныгыттылар. Моннан тыш аларга, Боз сараен арендага алып, тимераякта шуу мөмкинлеге тудырылды. Яшь мөселманнар өчен көненә өч тапкыр аш әзерләнде.

*Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды*

# "МӨХӘММӘДИЯ" МӘДРӘСӘСЕ

**Билгеле булганча, XIX гасыр ахырында иске, артта калган мәктәпләр күпкә яңарак, заманчарак уку йортларына алыштырылалар. Патша Россиясендә дөньяви татар мәктәпләре ачуга киртәләр булуын билгеләп узыйк. Шул ук вакытта алдынгы карашлы, яңа ысул белән укыта торган мәктәпләр ачуга кискен зарурлык барлыкка килә. "Мөхәммәдия" мәдрәсәсен ачу нәкъ менә шул дәвергә туры килә, ул заман таләпләренә җавап буларак төзелә.**



"Мөхәммәдия" мәдрәсәсе Россия татарлары арасында иң билгеле уку йортларының берсе була. Аңа күренекле дин галиме, мәшһүр җәмәгать эшлеклесе, педагог Галимҗан Мөхәммәтҗан улы Баруди (Галиев) нигез сала. XX гасыр башында ул күренекле мәгърифәтче, реформатор һәм философ буларак та билгеле. Мәдрәсә бинасын төзү берничә этаптан тора. 1882 елда Г.Барудиның әтисе буе 16 м, иңе 8 м булган бер катлы таш бинага нигез сала. Аңа нигез салучы хөрмәтенә һәм аның фамилиясенә бәйле рәвештә бу мәдрәсә "Галиев мәдрәсәсе" дип йөртелә. Ләкин мәдрәсә ачылуның беренче елында ук шәкертләрнең саны шулкадәр артып китә ки, алар хәтта бинага сыймый башлыйлар. Бу Мөхәммәтҗан әфәндене идән астын да мәдрәсә итеп яраклаштыруга этәрә. Ул аңа тәрәзәләр куйдыра. Шуннан соң шәкертләр аскы катка да урнаша башлыйлар. Кызганыч, 1898 елгы янгын вакытында бинаның агачтан эшләнгән өлеше тулысынча янып юкка чыга. Шул вакыйгадан соң бераз вакыт үткәч, Барудиның танышлары ярдәмгә килә. Алар бай һәм абруйлы кешеләр була, аларның ярдәме белән мәдрәсәнең яңа таш бинасы төзелә, бу бина ике катлы була. "Мөхәммәдия"нең даны Россия мөселманнары арасында тиз тарала һәм, бераз вакыт узганнан соң, мәдрәсәнең яңа бинасында да шәкертләргә кысан була башлый. Бер татарлар гына түгел, ә башкортлар, кыргызлар, калмыклар һәм төрки халыкларның башка вәкилләре дә бу мәдрәсәдә белем алырга тырышалар.

"Мөхәммәдия" мәдрәсәсе эшчәнлегенең иң әһәмиятле өлешләреннән, иң беренче чиратта, шунысын күрсәтергә кирәк: ул үзенең 36 ел эшләү дәверендә милли тормыш өчен кирәкле меңнәрчә югары квалификацияле кадрлар әзерләп чыгарган. Алар милләтнең күрке һәм горурлыгы булганнар. Алар арасында без инкыйлабта зур эшчәнлек күрсәтүче һәм демократия өчен көрәшүчеләрне (Х.Ямашев, М.Дулат-Гали, К.Якуб, К.Туйбактин, С.Габбасов), могтәбәр әдипләрне (Г.Камал, Ф.Әмирхан, М.Гафури, Ф.Борнаш, К.Тинчурин, З.Бәшири, М.Укмаси, Ә.Исхак, Ә.Камал, Ф.Әсгать, Ф.Туйкин), галим һәм җәмәгать эшлеклеләрен (Г.Ногайбәк, Г.Шәрәф, Х.Бәдигый, Ә.Рәхим, Г.Гобәйдуллин), гуманитар-энциклопедистны (Н.Исәнбәт), мәгърифәтче-педагогларны (Т.Ильяс, З.Шакиров, М.Галиев), инкыйлабчы, шагыйрь, полиграфистны (М.Алмаев), археограф һәм педагогны (С.Вахиди), журналист һәм нәширләрне (Б.Шәрәф, Ә.Хәсәни), югары ранг дипломатларын (Х.Биккенин, И.Әмирхан), билгеле артистларны (З.Солтанов, Габдрахман Камал, Габдулла Камал), атаклы композиторларны (С.Габәши, С.Сәйдәшев), рәссам-скульптор Б.Урманчены һәм башка бик күпләрне очратабыз.

Биш йөз шәкерт укыган бу уку йортының мөгаллимнәр составы үз заманы өчен шактый зур булган. Мәсәлән, 1906 елда, берничә ассистентны исәпкә алмаганда, монда егермегә якын мөгаллим эшләгән. Күрше "Гаффария" мәдрәсәсендә, хәтта 1914 елда да нибары биш мөгаллим булган. Архив материаллары буенча, 1913-1914 нче уку елында "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенең мөгаллимнәр составы егерме кешедән торган. Алар арасында шундый мөгаллимнәр булган: Г.Баруди-Галиев (Коръән тәфсире, хәдисләр); Г.Галиев (Коръән); М.Хәнәфиев (әлифба, Коръән, гакыйдә, ислам тарихы); Т.Ильяс (фикъһе, гарәп әдәбияты һәм гарәпчә уку, инша, догматика, шигърият, гакыйдә, хәдис һәм әхлак); Я.Адутов (Мөхәммәд галәйһиссәлам тормышы, гарәп әдәбияты); Ш.Бикбулатов (Коръән, гарәп этимологиясе, гакыйдә); Х.Газизов (гарәп этимологиясе, уку, тәрҗемә, диктовка, хәдис, гомуми тарих, татар теле); К.Биккенин (этимология, гарәп теле синтаксисы, арифметика, тәрҗемә, диктовка, уку, табигый тарих, гарәп ритмикасы, инша); М.Хәбибрахманов (арифметика, география, татар тарихы, татар теле); Ш.Мостафин (арифметика, матур язу, рәсем, Мөхәммәд галәйһиссәлам хәдисләре, уку, диктовка, гарәп теле, инша); Х.Солтанов (рус теле, арифметика); Ә.Заһитов (ислам тарихы, рәсем, арифметика, хисап, этимология, диктовка, география, Мөхәммәд галәйһиссәлам хәдисләре, Коръән, уку); З.Уразаев (ятлау, диктовка, рәсем, Коръән, уку, күчермә, хәдис, гарәп теле, матур язу, хисап, арифметика, ислам тарихы); И.Җәләлетдинов (диктовка, матур язу, Коръән, гакыйдә, уку); М.Мөхәммәтзакиров (гарәп теле этимологиясе, тәрҗемә, диктовка, уку, татар теле, ислам тарихы, табигый тарих); В.Булатов (көйләп Коръән уку, матур язу); Ә.Нигъмәтуллин (рәсем, уку, гакыйдә, күчермә, ятлау, матур язу, арифметика, хисап, диктовка); К.Тәрҗеманов (хокук нигезләре, татар теле, философия, психология, логика); Ә.Кәримов (Мөхәммәд галәйһиссәлам хәдисләре, гарәп әдәбияты); С.Нигъмәтуллин (гакыйдә, арифметика, татар теле).

1901 елда шәһәр мэры Лебедев мәдрәсәнең өч катлы бинасын төзергә рөхсәт бирә. Баруди мәдрәсәдәге тормыш рәвешен ул вакытларның санитар-гигиена таләпләренә туры китерү өчен күп көч куя. Мәдрәсәнең ашханәсе, кухнясы, шифаханәсе, аяк киемнәре төзәтү кярханәсе, урманчылыгы, китап төпләү кярханәсе, үз бакчасы була. Кышын талиблар (шәкертләр) тимераякта шуу өчен бакчада шугалак эшлиләр. Мәдрәсә каршында төп бинадан тыш үз укуларына түли алмаган ярлы балалар өчен мәктәп тә эшли. Мәдрәсә үз исәбенә талибларга бушка махсус кием, уку әсбаплары бирә, хәтта стипендия дә түли. Ачылган вакытта "Мөхәммәдия" башка уку йортларыннан берни белән дә аерылып тормаган. Бары тик Г.Баруди тырышлыгы белән генә уку программасына илаһият һәм гарәп теле кебек яңа дисциплиналар кертелә. Алга таба "Мөхәммәдия" талиблары "Мөхәммәдия", "Телескоп", "Манзарател-галәм", "Телчән" кебек үз газеталарын чыгара башлыйлар. Талибларның үз театрын булдыру идеясе барлыкка килә. Һәм, билгеле булганча, 1906 елда мәдрәсәнең үз профессиональ театры оеша.

1891 елда, мәдрәсәдә яңа укыту ысулы кертелгәч, анда математика, география, табигать белеме, рус теле кебек дөньяви предметлар да укытыла башлый. Ел саен дөньяви фәннәрне укытуга зарурлык арта бара. Шулар белән параллель рәвештә югары квалификацияле укытучылар да әзерләргә кирәк була. Шул максатларда 1907 елның 2 маенда педагогик курслар ачыла. Нәтиҗәдә уку йорты күпбаскычлы мәдрәсәгә әйләнә, анда 12 ел укый башлыйлар. Ә 1913 елдан мәдрәсә тагын үзгәртелә һәм ундүртьеллыкка әйләнә: 5 ел "Ибтидаия" - башлангыч мәктәп, 6 ел "Санавия" - урта белем, 3 ел "Галия" - югары һәм чыгарылыш курсы. Аннан тыш, укыту системасына кертелмәгән берьеллык әзерлек курслары да була. "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе татарлар арасында гына түгел, ә бар төрки халыклар арасында да киң танылу ала. 36 ел эшләү дәверендә ул меңнән артык талиблар әзерләп чыгара, аларга башлангыч, урта, югары рухи белем бирә. "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе татар мәгарифе тарихында якты эз калдыра, фән, мәдәният, икътисад, сәясәт өлкәләренә караган зур белгечләр, галимнәр әзерләп бирә.

Ләкин "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе тарихында барысы да шома гына бармый. 1918 елда мәдрәсә куып таратыла, аның бинасы төрле совет оешмаларына тапшырыла. Мәдрәсә, бик озак эшләми торганнан соң, бары тик 1993 елда гына яңадан ачыла.

Мәдрәсәне оештыручы - Татарстан мөселманнары Диния назарәте. Ә хәзерге тарихи бина бу уку йортына бары тик 1998 елда гына кире кайтарылды. Бу бинаның мәдрәсәгә кире кайтарылуында Ислам дине кабул итүгә мең ел исемендәге Казан мөселман мәдрәсәсенең ул вакыттагы директоры Исхак хәзрәт Лотфуллинның өлеше зур булды.

Бүгенге көндә мәдрәсәдә урта гомумбелем бирү мәктәпләрен тәмамлаган укучылар "Ислам фәннәре һәм тәрбия" белгечлеге буенча белем (югары рухи белем) алалар. Дини дисциплиналар белән бергә, гарәп, татар, инглиз телләре, психология, педагогика, чит телләр укыту методикасы, риторика, информатика кебек предметлар да бу уку йортының уку планына кертелгәннәр.

Мәдрәсәдә дәреслекләре, курс һәм диплом эшләрен әзерләр өчен җитәрлек дәрәҗәдә әдәбияты булган китапханә эшли. Уку максатларында талибларга аудио/видео кассеталар тәкъдим ителә, бар талиблар да алардан файдалана ала. Чит шәһәрләрдән килүчеләрне мәдрәсә тулай торак белән тәэмин итә. Мәдрәсәдә даими рәвештә Коръәнне яттан белү һ. б. темалар буенча группалар, курслар, талиблар арасында бәйгеләр үткәрелә, кул эшләре, рәсем сәнгате үрнәкләре буенча күргәзмәләр оештырыла. ШТК (русча әйткәндә КВН. - ред.), башка вузлар белән футбол, теннис, баскетбол, волейбол, җиңел атлетика һ. б. спорт төрләре буенча ярышлар үткәрү инде традициягә әйләнде, дини темаларга конференцияләр һәм танышу, күңел ачу экскурсияләре үткәрелә.

**Чыганак: www.muhammadiya.ru**

# ВАКЫТЫГЫЗНЫҢ КАДЕРЕН БЕЛЕГЕЗ!

*(Ахыры. Башы газетабызның 2013 елның 4 гыйнвар санында.)*

### Гамәлләрсез белемнәр - акылдан язу, ә белемсез гамәлләр ул - булмый торган әйберләр

Гали (рг) әйткән: ***"Гамәлләрсез белемнәр - акылдан язу, ә белемсез гамәлләр ул - булмый торган әйберләр".***

Акылдан язганнар исәбендә булмас өчен, без изге гамәлләр эшләүгә күбрәк игътибар юнәлтергә тиешбез. Тик бу өлкәдә уңышка ирешер өчен, безгә үз вакытыбызны контрольдә тотарга һәм гамәлләребезне вакыт шкаласы буенча дөрес бүләргә өйрәнергә кирәк.

Гамәлләрнең кыйммәте күп факторларга бәйле. Һәм аның кыйммәтен шактый арттыра торган шундый факторларның берсе - ул гамәл кылынган вакыт.

Коръәндә билгеле бер вакыт аралыклары турында искә алына. Ул вакыт аралыкларының, вакытның мөһим булуы турында дәлилләр. Изге Коръәндә Аллаһ берничә тапкыр вакыт белән ант итә. Мәсәлән, Аллаһы Тәгалә көн белән, ә кайвакыт төн белән дә, кояш чыгышы, шәфәкъ алды вакытлары белән дә ант итә.

Коръәндә шулай ук айлар искә алына, алар арасында дүртесе аеруча аерып күрсәтелгән. Ул айлар арасында ураза ае - Рамазан да бар. Җомга көн һәм Кадер киче аерым искә алынган.

Болар барысы да вакытның әһәмияте дәлилле һәм Изге Китапта әйтелгән вакыт аралыкларын дөрес итеп файдалана белүнең зарурлыгы турындагы фикергә китерә.

Аллаһның Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) әйткән: ***"Аллаһның иң сөйгән коллары - кояш һәм айның хәрәкәте артыннан күзәтеп баручылардыр***. Ягъни үз тормышларының һәр мизгелен бу вакытта иң кирәкле булган гамәлне башкарырга тырышучылары - иң сөелгәннәре. Кайсы вакытта кайсы гамәлне башкарырга кирәк икәнен Рәсүлебез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) хәдисләре аша ачыкларга була. Хәдисләрдә кайсы гамәлләрне кайсы вакытта башкарырга, алда искә алынган ул вакыт аралыкларын ничек итеп дөрес файдаланырга икәнлеге тәфсилләп аңлатылган.

Үзенең киләчәге турында кайгырткан һәм бар омтылышлары бу фани дөнья белән генә чикләнмәгән һәркемгә бу мәсьәләне җентекләп өйрәнергә һәм тормышның һәр мизгеленнән мөмкин кадәр күбрәк файда алып калырга тырышырга кирәк.

Мин эшне имам әл-Газзәлинең "Хак юлга басу буенча күрсәтмәләрнең башлангычы" китабын укудан башларга киңәш итәр идем. Китапта йокыдан уянганнан алып йокларга ятканга кадәрге һәр вакыт аралыкларында нинди гамәлләр кылуның һәм аларны ничек итеп башкаруның өстенлекләре турында җентекләп аңлатыла. Китап рус теленә тәрҗемә ителгән һәм бу китапны укып чыккан кеше үзенә күп файда алачак.

### Вакытның кадерен барысыннан да күбрәк белүчеләр

Хәсән әл-Басри: ***"Миңа үз вакытларына карата динарлар һәм дәрһәмнәргә караганда да күпкә комсызрак булган кешеләрне күрергә туры килде"***, - дигән.

Хәсән әл-Басри табигыйннардан булган, ягъни ул сүз алып барган кешеләр я сәхабәләр, я табигыйннар булган. Сәхабә һәм табигыйннардан бу сыйфатны алдагы гасырларда үзләренә иң күп алучылар - суфилар булганнар.

Суфичылыкның күп төрле билгеләмәләре бар. Аларның берсе: ***"Суфичылык - һәр мизгелне бу мизгел вакытында иң өстенлекле булган гамәл башкару өчен файдалану"***, - дигән.

Гомәр әл-Макки билгеләве буенча: "Суфичылык ул - Аллаһның колы һәр мизгелдә бу мизгел өчен мөмкин булган гамәлләрдән иң өстенлеклесе белән мәшгуль булуы".

Иң зур галимнәр суфичылыкның бу сыйфатын таныганнар һәм вакытларының һәр мизгелен нәтиҗәле файдаланырга өйрәнү өчен суфиларның мөридләре булып киткәннәр.

Гамәлләрнең кыйммәте күп факторларга бәйле. Алда без гамәлләрнең вакыт белән бәйле икәнлеге турында сүз алып барган идек. Тик гамәлләрнең кыйммәтен билгеләү өчен тагын бер төп фактор бар. Ул - бу гамәлне башкарган вакытта аны башкаручының халәте.

Ике кеше дә бер үк гамәл кылырга мөмкин, мәсәлән, алар икесе дә намаз укыйлар, ди. Тыштан караганда, аларның икесе дә бертөрле кебек күренергә мөмкин. Тик шулай да, алар арасындагы аерма күк белән җир арасындагы кебек тә булырга мөмкин. Барысы да бу гамәл кылучыларның нинди ният алып аны башкаруларына һәм аны башкарган вакыттагы эчке халәтләренә бәйле.

Безнең күбебез өчен иң мөһиме - гамәл башкару: намаз, Коръән уку, искә алу йоласы, сәдака тарату һ. б. Әгәр дә бу гамәлне кылган вакытта: "Рухи халәт нинди булырга тиеш?" - дип сорау бирелсә, безнең кайсыбыз бу сорауга җавап бирә алыр иде икән?! Ә бит бу - без кылган гамәлләрнең кыйммәтен күп мәртәбәләр арттыра торган әйбернең үзе бит инде.

Гамәлләрне кылган вакытта эчке халәтнең ничек булырга тиешлеген белергә теләгән кешегә әл-Газзәлинең "Иман турындагы фәннәрнең яңадан тууы" китабын укырга киңәш итәр идем. Бу гаҗәеп китап, аны укып чыгып, сез кылган гамәлләрегезнең, гәрчә сез аларны башкару өчен күп көч-тәннәрегезне сарыф итсәгез дә, камиллектән никадәр ерак икәнлеген аңлый аласыз.

### Планлаштыру, контроль, анализ…

Безнең тормыш кай ягы беләндер сәүдәгә охшаш. Сәүдәдәге кебек үк без төп капиталга - вакытыбызга иябез. Безнең табышка чыгу яки инде зыянга эшләвебез аны ничек итеп файдалана белүебезгә бәйле. Теләсә кайсы эшмәкәр үзенең эшләрен планлаштырырга һәм аннан соң аны анализларга кирәк икәнен белә. Һәр эшмәкәр шул анализ нәтиҗәсендә алга таба үзенә ничек эш кылырга кирәклеген ачыклый. Шуның кебек үк без дә кыла торган гамәлләребезне планлаштырырга, аларны контрольдә тотарга, аннан соң анализларга тиешбез.

Иң беренчесе - без үзебезгә эшләнәсе эшләрнең программасын төзеп куярга тиешбез. Әлбәттә, бу программа Аллаһның Рәсүленнән (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) безгә кадәр килеп ирешкән белемнәр белән туры китереп төзелергә тиешле. Шул ук вакытта, бу программабызның матдәләрен башкарып чыгу безгә нәрсәләр китерәчәген дә аңларга тиешбез. Аның ни өчен эшләнүен һәм ниләргә китерәчәген аңламыйча, ни дә булса эшләү - бик авыр эш. Бу эш башта, соңыннан гадәткә әйләнеп киткәнчегә кадәр аеруча авыр. Шуңа да баштагы этапта, планлаштырган ул гамәлләребезнең зур кыйммәткә ия булганын үзеңнең исеңә төшереп тору - аеруча мөһим. Әгәр дә безнең өебезнең күренеп торган урынында көндәлек режим эленеп торса, бик яхшы. Ә андагы планлаштырылган һәр матдә каршында, аның кыйммәтен аңлатучы Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) хәдисләре яки галимнәрнең әйтемнәре дә торса, аеруча яхшы.

Мәсәлән, әгәр без, беренче матдә итеп, "Таң атканчы торырга һәм намаз укырга", - дип язганбыз икән, монда бу вакытның әһәмиятен дәлилләүче һәм намазны шул вакытта уку лазем икәнен аңлатучы хәдисләрне язып куябыз. Әгәр дә уянгач һәм йоклар алдыннан без бу хәдисләрне укып чыгабыз икән, безнең бу вакытны Аллаһка табынып үткәрергә булган теләкләребез артачак кына.

Шулай ук йоклар алдыннан режимны укып чыгып, безгә бу расписаниене үти алу-алмавыбызга анализ ясау да лазем. Әгәр дә планлаштырылганның барысын да эшли алгансың икән, игелекле гамәлләр башкарырга ярдәм иткән өчен Аллаһка рәхмәтләр яудырырга кирәк. Әгәр дә инде ният ителгәннәрнең барысы да эшләнеп бетмәгән булуы, яки тагын да начаррагы - берәр килешсез эш тә эшләнгән булуы ачыкланса, шунда ук тәүбә итәргә кирәк һәм мондый эшләр өчен, мөмкинлегеңә карап, үз-үзеңә ниндидер җәза бирү тәртибе урнаштыру да яхшы.

Мисал өчен, сез иртәнге намазга вакытында тора алмадыгыз, ди. Сезгә бу көнне моның өчен ураза тотарга яки мөлкәтегезнең ниндидер бер өлешен Аллаһ юлында тотарга була. Шул ук вакытта без үз-үзебезгә икенче көнне расписаниедәге бар матдәләрне дә башкарып чыгарга тырышуны максат итеп куярга тиешбез. Һәм шулай итеп, һәр көн саен без бу фани дөньяны ташлап киткәнгә кадәр шул эшләрне башкарырга тиешбез.

Без һәр яңа көнне яңа шартларда башлап җибәрәбез. Баймы без, әллә ярлымы, безнең барыбыз карамагында да 24 сәгать. Бәяләп бетереп булмаслык бу ресурсны һәркем үзенчә файдалана һәм безнең Хисап көнендәге хәлебез дә без аны ничек итеп сарыф итүебезгә бәйле.

Бу көнне кешеләр бу дөньяда җыйган бар байлыкларын да Аллаһның берлеге турындагы гыйбарәне әйтер өчен җитәрлек булган берничә секундка алмаштырырга әзер булырлар, тик инде андый мөмкинлек аларга бүтән бирелмәс.

Ә ул вакытта башкалар хозурлыкта булыр. Аларның хәтта йокылары да, башкалар дөньяви дип исәпләгән гамәлләре дә, аларга Аллаһка табыну булып язылыр. Һәм дә алар, шиксез, тормыш мизгелләренең кадерен белгән, вакытларын бушка сарыф итмәгән кешеләр булырлар.

**Фәһим хәзрәт ӘХМӘТҖАНОВ,**
**Татарстанның көньяк-көнбатыш төбәге казые, Чүпрәле районы имам-мөхтәсибе**

# ОЛУГ ГАЛИМ ВӘ ФИКЕР ИЯСЕ

*(Дәвамы. Башы 1 нче биттә.)*

дәрвиш булып, михнәтләр, җәбер-золымнар чигеп, аларны үз җилкәсендә татып, гади халык арасында бер каладан икенчесенә күченеп йөреп гомер кичерә.

Хәер, ул заманнарда Шәрык идарәчеләре, төс-кыяфәтен үзгәртеп, иңнәренә ямаулы чикмән элеп, халык арасына, базарларга чыгудан тайчанмаган. Максат бер - җәһил вә ялагай ярдәмчеләрнең чынбарлыкны купайтуыннан гарык булып, гавам сулышын тою, хакыйкатьтә гади халыкның ничек яшәве белән якыннан танышу. Илбашы тәхете тирәсендә кадер-хөрмәттә көн күргән ошбу олуг галим вә фикер иясенең шушы гамәле аның биографларын бүгенгәчә гаҗәпкә калдыра. Яланаяклы киндергә төренгән, биштәр аскан мосафир үзе кебек аркадашлары һәм мөридләре белән Сүрияне гизә, әл-Кодс (Иерусалим) һәм Искәндәрия (Александрия) калаларына сәфәр кыла. Биштәрендә кибеп беткән арыш икмәгенең кыерчыгы белән галимнең исемен гасырларда мәңгеләштергән дүрт калын кульязма дәфтәр йөри. Ислам дине тарихында әлеге фундаменталь хезмәт - "Иман турында фәннең яңадан торгызылуы" ("Воскрешение наук о вере"). Галим анда суфыйчылык тәгълиматын вә ортодоксаль исламны килештерүгә ирешә. Һәм шуның өчен ул исән чагында вә бакыйлыкка күчкач тә, Исламга яңа сулыш бирүче буларак таныла. Ниһаять, фарсы тәхете тирәсендәге ыгы-зыгылар тына һәм ил белән идарә итү Мәлик шаһның улы - солтан Баркьярук кулына күчә. Әлбәттә, шаһның баш вәзире итеп Низам әл-Мөлекнең улы Фәһр әл-Мөлек билгеләнә. Нәкъ менә шушы яшь вәзир, Газзәлине эзләтеп, шаһ сараена кайтара һәм аны остаз итеп, университетка билгеләтә. Галим һәм философ алты ел дәвамында мәгърифәт нурын тарата. Шуннан соң туган якларына - Хорасанга - үзенең туган шәһәренә кайтып хөрмәткә - суфыйларның рухи җитәкчесе - шәех дәрәҗәсенә ирешә, әмма үзенең мәктәп-мәдрәсәсен ачарга өлгерми кала, 1111 елда 53 яшендә "дарелфәнәдан дарелбакыйга күченә". Моннан нәкъ тугыз гасыр элек яшәгән галим һәм җәмәгать эшлеклесе, педагог һәм остазның фикерләре, карашлары, аның хезмәтләре еллар аша урта гасырларда ук Европага барып ирешә, бөек немец философы Гегель тарафыннан да бик югары бәяләнә.

Газзәлинең югарыда телгә алынган хезмәте бихисап бүлекләрдән гыйбарәт. Аның беренче бабы "Белем турында китап" дип исемләнгән. Андагы беренче җөмләне искәртеп китү урынлы булыр:

"Хак Тәгаләнең Илчесе, аңа Аллаһның рәхмәте вә мәрхәмәте ирешсен, әйткән:

- Гыйлем эстәү - һәр мөселман өчен фарыз! Белемне хәтта Кытайга да барып эзләгез!"

Әлбәттә, сөекле Рәсүлебез Мөхәммәднең (гсв) әлеге сүзләре мөселманнарга гына атап әйтелмәгән, чөнки гыйлем - Җәнабел Хакка илтә торган үзәк юлларның берсе ул. Шушы гыйлем ияләренең берсе фарсы Газзәли, борынгы гыйбрани (яһүд) һәм юнән (грек) телләрендә иҗат ителгән чыганакларны укып, үзенең китабын гарәп телендә язган.

Акыл иясенең фикеренчә, иң югары күрү сәләтенә кеше күзе түгел, хакыйкатьтә адәм баласының акылы ия, чөнки күз, әйләнә-тирәдәге җисемнәрнең асылына үтмичә, аларның тышчасын гына иңли, ә кеше акылы өчен кояш ролен Җәнабел Хактан иңдерелгән изге Коръәни-Кәрим үти.

Философның хөкемдарларга турылап әйткән уй-фикерләре бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмыйча, васыять буларак кабул ителә. Менә бер өзек:

"Бел һәм аңла, солтан, гаделлек урнашу акылның тулылыгыннан. Ә тулы акылга ия булу - димәк, әйберләрне ничек бар шулай күрү, асылына төшенү һәм тышкы кыяфәтенә алданып ялгышмау. Әйтик, әгәр син җирдәге тормышның хакына кешеләрне рәнҗетәсең икән, яшәвеңнең максаты нәрсәдә икәнен аңларга тиешсең. Әгәр максатың тәмле ашау булса, бел: бу - хайвани теләк, чөнки ашау-эчүдәге

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# Мәчеттә яланаяк һәм башка түбәтәй кими намаз уку мәкруһ гамәл булып исәпләнәме?

**Бу дөньяда барысына да, Хисап көнендә иманлыларга гына рәхим-шәфкатьле Аллаһ исеме белән.**

Бар мактаулар, чынлап та, Аллаһка гына. Без мактыйбыз Аны, Аннан ярдәм һәм ярлыкавын сорыйбыз, күңелләребез һәм гамәлләребезнең явызлыкларыннан Аңа гына сыенабыз. Аллаһ юлыннан барган кешене беркем дә юлдан яздыра алмас, Аллаһ юлыннан бармаганының рухи остазы юктыр. Аллаһтан башка иләһ юклыгына, Аның иптәше юклыгына шәһадәт итәбез. Шул ук вакытта Мөхәммәднең (сгв) Аның колы һәм Рәсүле икәнenә дә шәһадәт итәбез.

Иң баштa Әбу Давыд җыентыгында 650 нче номер белән күрсәтелгән хәдисне укып чыгыйк.

Әбу Сәед әл-Хөдрий (рг) сөйләп калдырган: "Аллаһның Рәсүле (сгв) үзенең сәхабәләре белән намаз укыган вакытта, аяк киемен салып, үзенең сул ягына куйган. Һәм, моны башка кешеләр күргәч, алар да үз аяк киемнәрен салып куйганнар. Аллаһның Рәсүле (сгв.) намаз укып бетергәч: "Сез нигә аяк киемнәрен салдыгыз?" - дип сораган. Алар: "Без синең аяк киемеңне салганыңны күргәч, үзебезнекен дә салып куйдык", - дип җавап биргәннәр. Һәм Аллаһның Рәсүле (сгв): "Чынлыкта, Җәбраил (гс) фәрештә минем янга килеп, анда нәҗес бар дип әйткән иде", - дигән. Аннан соң: "Әгәр дә кем дә булса мәчеткә килә икән, аягына кигән әйберендә пычрак (казар) яки шакшылык (аза) бармы-юкмы икәнен карасын, әгәр дә аяк киемендә пычрак һәм шакшылык бар икән, аны тазартсын һәм аның белән намаз укысын", - дип әйткән.

Игътибар итегез: Аллаһның Рәсүленең (сгв) яланаяк намаз укуының сәбәбе шунда: аның аяк



киеменең пычрак, башка сүзләр белән әйткәндә, нәҗесле булуында. Ә үзенең сәхабәләренә ул аяк киеменең чиста булу шарты белән, аяк киемнәрен салмыйча гына, намаз укырга тәкъдим иткән.

Шул ук җыентыкның 652 нче номерлы хәдисендә болай диелгән:

Йаглә бине Шаддад бине Аус үзенең әтисе сөйләгәнен китерә: "Аллаһның Рәсүле (сгв): "Яһүдиләрнең киресен эшләгез, чөнки алар, чынлап та, үзләренең сандали һәм читекләрендә намаз укымыйлар".

Чынлап та, яһүдиләрнең гыйбадәт кылуының нигезендә яланаяк гыйбадәт кылу ята. Аларны? яланаяк укуларны? сәбәбен без "Та һа" сүрәсенең 12 нче аятендә Аллаһы Тәгаләне? Муса галәйһиссәламгә булган боерыгында күрәбез: "(Ий Муса!) Синең Раббың, әлбәттә, Минмен, башмакларыңны сал, чөнки син Тува исемле мөкатдәс үзәнлектә".

Әйе, яланаяк гыйбадәт кылу - яһүдиләрнең төп үзенчәлеге. Мөхәммәд (сгв) өммәтенә исә, аякларга киеп намаз уку тәкъдим ителгән. Ул калын, нык аяк кимеме, әллә инде юка оеклармы, моның әһәмияте юк. Фәкать аяк киеме чиста, пакь булырга тиеш. Безне яһүди һәм христианнардан аерып тора торган бу өстенлек Мөхәммәд (сгв) өммәтенә Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән бүләк. Моны шулай кабул итәргә кирәк. Өстәвенә, безнең сөекле Пәйгамбәребез (сгв) үзене? күп кенә хәдисләрендә безне яһүди һәм христианнардан аерылып торырга да өнди. Бу турыда хәдисләр җитәрлек булса да, без сезгә шуларның бары тик берничәсен китерү белән генә чикләнәбез.

Ибне Умардан (Аллаһ аңардан риза булсын!) тапшырыла, ул шундый сүзләр әйткән: "Аллаһның Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!): "Кемниндидер халыкка охшарга тырышса, ул шулардан саналыр", - дигән (Әбу Давыд. Китабел либас, № 4031).

Шулай итеп, пәйгамбәребезнең (сгв) нәсихәтләренә буйсынып, яһүдиләрдән һәм насаралардан аерылып торыр өчен, без аякларыбызга оекбаш һәм читек кебек аяк киемнәре киеп кенә намаз укырга тырышабыз. Безне? гыйбадәтебез яһүд һәм насара дин әһелләрене? гыйбадәтеннән яланаяк укымау белән генә түгел, бәлки яланбаш укымау белән дә аерылып тора. Чөнки пәйгамбәребез (сгв) һәрвакыт башына чалма кигән рәвештә генә намаз укыган. Сәхабәләр аны бер генә тапкыр, анысын да чалмасын юу сәбәпле генә, чалмасыз көе күргәннәр. Ә хаклыкта, бу - безне? гыйбадәтебезне яһүд һәм насараларны? гыйбадәтеннән аерып тора торган бер билге. Әгәр дә инде сез моңа ышанып бетмисез икән, чиркәүгә үз гомерендә бер генә тапкыр булса да кергән теләсә кайсы христианнан сорый аласыз, ул сезгә, шиксез, чиркәүгә кергән һәр ир-ат баш киемен мәҗбүри салырга тиеш дип әйтер.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Аллаһтан курыккан кеше аның боерыкларын үтәргә, Пәйгамбәребез (сгв) сөннәтләренә иярергә тиеш. Намаз - безгә йөкләтелгән и? зур гыйбадәт. Бу гыйбадәтне үтәгәндә без бигрәк тә фарыз һәм вәҗиб гамәлләргә генә түгел, бәлки сөннәт һәм мөстәхәб гамәлләргә дә игътибарлы булырга тиешбез. Онытмыйк: намаз Раббыбыз белән булган и? якын урын, и? якын вакыт. Тышкы кыяфәтебезне шикләнмичә без үти алабыз. Һәм аны мөмкин кадәр үтәргә тырышырга кирәк. Эчке халәтебез - кешегә күренми торганы, шайтан төрле уй-фикерләр белән читкә алып китә торганы, хәтта намазны бозылыр дәрәҗәгә җиткезә. Тышкы кыяфәтебез җитәрлек дәрәҗәдә булмаса, шайтанга эчке халәтебезгә тәэсир итү җи?елрәк була. Шу?а күрә ку?елдә булганы җитә, дип, тәкәбберләнеп йөрергә кирәк түгел.

Без, хәнәфиләр, яланаяк, яланбаш намаз укуны мәкруһ гамәл дип исәплибез. Без артыгына дәгъва итмибез, гәрчә галимнәр арасында бу мәсьәлә буенча төрле фикер каршылыклары булса да, бу эш тыелган, хәрам гамәл дип расламыйбыз.

Бу турыда имам Мөхәммәд үзенең "әл-Әсл" китабында искә алган, ул имам әс-Сарахсиның "Мәбсут" китабына кертелгән. Шулай ук "Миркател Мафатих" китабында да бар, ул "Мишкател Мәсабих" китабының шәрехе. Мулла Гали әл-Кари әйткән: "Галимнәр арасында читек киеп намаз уку, аның мәкруһмы, мөбахмы яки мөстәхәбме булуы турында бәхәсләр урын алган. Тик, яһүдиләрдән аерылып тору ниятендә, берничә тапкыр гына булса да, моны эшләү кирәклеге турында бернинди фикер каршылыклары да юк. Шулай итеп, без, читек киеп намаз укуны, ким дигәндә, мөбах яки мөстәхәб гамәл дип исәпли алабыз".

Әгәр дә инде, намазны оек киеп уку файдасына булган алда күрсәтелгән дәлилләр, хәтта булмасалар да, без барыбер Россия мәчетләрендә аякларыбызга оеклар киеп намаз укырга өндәгән үзебезнең имамнарыбыз сүзләренә колак салырга тиешбез. Безгә биш вакыт намазларын калдырмаган мөселман табиблары белән еш аралашырга туры килде, алар мәчетләрдә гөмбәчек авырулары таралу ихтималлыгы турында бертавыштан белдерәләр. Баш киеме белән намаз уку гыйбадәтебез белән генә бәйле булса, аякка киеп намаз уку медицина күзлегеннән караганда, гыйбадәт белән бәйләмәгән очракта да, бернинди бәхәскә урын калдырмый, хәтта мәҗбүрилек дәрәҗәсенә күтәрә. Безнең мәчетләребез - җәмәгать урыннары, динебез һәрберебездән чисталык таләп итә, шуңа да анда чисталык саклау һәм гыйбадәт кылу өчен комфортлы һәм хәвефсез шартлар тудыру - безнең бурычыбыз. Кайбер мәчеткә йөрүчеләрнең оекбаш киеп намаз укуга җиңел караулары аркасында, кайбер мөселман туганнарыбызның гөмбәчек авырулары йоктыру очраклары чынлап та билгеле.

Бу мәкаләнең ахырында, без, оек та кимичә, һәм, шиксез, түбәтәйсез намаз укуда тырышлык күрсәтүче үзебезнең мөселман туганнарыбызга үзегезнең гыйбадәтегез вакытында яһүди һәм христианнарга охшарга тырышмагыз, алардан аерылып торыгыз дип мөрәҗәгать итәсебез килә. Әлбәттә, сезне бу гамәлгә, "башкалардан аерылып тор һәм сине күреп алырлар" кагыйдәсе этәргәнен без яхшы аңлыйбыз, тик шулай да, әйтегез әле, әллә инде сез, чынлап та, безнең мәчетләребездә ызгыш-талаш һәм җәнҗаллар чыгуының сәбәбе булырга телисезме?!

***Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН, Рөстәм хәзрәт ШӘЙХЕВӘЛИЕВ***

# ОЛУГ ГАЛИМ ВӘ ФИКЕР ИЯСЕ

*(Ахыры. Башы 1,3 нче битләрдә.)*

чамасызлык аларга хас. Әгәр максатың ефәк киемнәргә төренү икән, димәк, син ир-ат кыяфәтендәге хатын-кыз, чөнки һәртөрле бизәнүләргә омтылу һәм җиңел акыллылык - аларга тәс. Ә инде максатың бар ачуыңны дошманнарыңа түгү булса, син кеше кыяфәтендәге ерткычсың. Әгәренки кешеләрне үзеңә хезмәт иттерергә ирешмәкче икәнсең, димәк, син акыллы булып кыланучы ахмак, чөнки акылың булган очракта белер идең: сиңа хезмәт итүчеләр чынлыкта үз теләкләре һәм корсакларының коллары, һәм хакыйкатьтә аларның хезмәте һәм бил бөгүләре һич тә сиңа түгел, ә үз-үзләренә. Шуңа да алар, синнән, бүтән зат кулына хакимият күчү белән үк, сиңа арка белән борылачак: алар динар һәм дирһәм китерүче теләсә нәрсәгә хезмәт итүчеләр һәм мондый хезмәт - адәм көлкесе".

Әл-Газзәли - йөгерек телле, искиткеч мантыйкка ия булган, хикмәтле чагыштырулар ярдәмендә зур гомумиләштерүләргә ирешкән фикер иясе. Мәсәлән, ул, кяфер каберенә еланнар оя кора дигән риваятькә ышанып, кабер ачып, анда еланнар таппыйча аптырауучылардан каһкәһәләп көлә. Аның фикеренчә, гадәти тышкы еланнардан котылу, аларны куып чыгару дөрес гамәл, әмма ул еланнар дәһринең күңелендә мыжлый һәм алардан һәр ике дөньяда да берничек тә котылу әмәле юк... Тәмугта да бернинди дә ут янмый, анда килгүче һәркем үз утын үз күңелендә үзе алып килә, дип фараз кылган бөек дин белгече.

Суфыйларда урнашкан гадәт буенча, Газзәли үз акылы белән ирешкән хакыйкатьләрне кыйсса-риваятьләр аша укучыларга ирештерә. Менә шуларның берсе:

"Көннәрдән беркөнне Рәсүл-Әкрәмебез Мөхәммәд (сгв) мәчеттә сәхабәләре белән иртәнге намазда була. Араларында үтә дә хискә бирелүчән бер адәм бар икән. Мөхәммәд (сгв) Коръәни-Кәримнән бер сүрәне укый. Әлеге сүрәдә фиргавеннең: "Мин сезнең асыл Раббыгыз!" - дигән сүзләрне ишетүгә, әлеге кеше, нәфрәтләнеп:

- Эттән туган мактанчык, - дип ычкындыруын сизми дә кала.

Пәйгамбәр (сгв) намазын бүлдерми, шартын китереп укып бетерә.

Гыйбадәттән соң мәчеттәгеләр дәррәү:

- Әдәпсез! Шул сүзең белән син Җәнабел Хакны рәнҗеттең, Аның йортында тынлыкны бозу гына түгел, Аның Илчесе алдында начар сүзләр әйттең, - дип өстенә ябырылалар.

Теге бичара:

- Эш харап, болар мине ботарлап ташлыйлар бугай, - дип нишләргә белми, куркуыннан коелып төшә һәм бары тик Рәсүл (сгв) каршына Җәбраил фәрештә килеп баскач, бераз тын ала.

Җәбраил фәрештә исә:

- Җәмәгать, Аллаһы Тәгалә сезгә сәламен ирештерде һәм ошбу беркатлы мәхлүкны җәберләмәскә боерды, чөнки намаз кылучыларның әерым-аерым һәркайсының вә җөмләгезнең догаларына караганда шушы адәмнең ихластан әйтелгән тиргәү сүзләре Хак Тәгаләнең күңеленә тирәнрәк үтеп кергән, дип белдергән, имеш".

**Рөстәм МӘҺДИЕВ**
**Чыганак: www.islam-today.ru**

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 2 (171) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** № 35385.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 10 гыйнвар көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**